ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 г. Заинск № 70

**«2024 елга гражданнарны аз керемле дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында»**

Гражданнарны азкеремле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондындагы торак урыннарны социаль наем шартнамәләре буенча бирү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 49 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2024 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гражданны аз керемле дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен кушымта нигезендә расларга.
2. «Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында керемнең һәм мөлкәт бәясенең чик күрсәткечләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 мартындагы 179 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенә гражданнарны социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ дип таныганда кушымтада күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

5. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р. М. Хаҗиповка йөклим.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист

Кушымта

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 08.02.
70 номерлы карары
белән расланган.

**Гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаилә әгъзаларының һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткече**

| Гаилә әгъзаларының саны | Гражданны аз керемле дип тану максатларында гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының чик күрсәткече (сум) | Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең чик күрсәткече күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1 | 756887,40 | 21195,81 |
| 2 | 1513774,80 | 21195,81 |
| 3 | 2270662,20 | 21195,81 |
| 4 | 3027549,60 | 21195,81 |
| 5 | 3784437,00 | 21195,81 |
| 6 | 4541324,40 | 21195,81 |
| 7 | 5298211,80 | 21195,81 |
| 8 | 6055099,20 | 21195,81 |
| 9 | 6811986,60 | 21195,81 |
| 10 | 7568874,00 | 21195,81 |

Башкарма комитетның
эшләр идарәчесе Е.А.Васильева